**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2026 № 232

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясына таянып, «социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 16.03.2015 № 13-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның һәм салым салынырга тиешле, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән милке, шулай ук «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыгының 01.01.2026 елга бер квадрат метр торак урынның уртача бәясен билгеләү буенча эксперт-аналитик тикшеренүгә нигезләнеп һәм резидент физик затларга бирелгән ипотека торак кредитлары буенча уртача үлчәүле процент ставкалары һәм сроклары күләме турында Россия Банкы мәгълүматларын исәпкә алып, Башкарма комитет Тәтеш муниципаль районы карары:

1. Билгеләү:
1.1. гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:
1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 070 478,00 сум.;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 2 140 956,00 сум.;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 3 211 434,00 сум.;
1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен-4 281 912,00 сум.;
1.1.5. биш кешелек гаилә өчен-5 352 390,00 сум.;
1.1.6. алты кешелек гаилә өчен-6 422 868,00 сум.;
1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен-7 493 346,00 сум.;
1.1.8. сигез кешелек гаилә өчен-8 563 824,00 сум.;
1.1.9. тугыз кешелек гаилә өчен-9 634 302,00 сум.;
1.1.10. ун кешелек гаилә өчен-10 704 780,00 сум.;
1.1.11. унбер кешедән торган гаилә өчен – 11 775 258,00 сум.;
1.1.12. уникe кешедән торган гаилә өчен – 12 845 736,00 сум.
1.2. 2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына (ялгыз яшәүче граждан өчен) туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме: 23 327,00 сум.
2. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре

буенча торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда керемнең һәм мөлкәт хакының әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән максималь күләменнән файдаланырга.
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче**

**И.А. Садриев**